| СОВЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
|---|---|---|
| **РЕШЕНИЕ**<br>**31.10.2024** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 431** |

Зеленодольск муниципаль районы Советының 2018 елның 9 июлендәге 313 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында хезмәт (вазыйфаи) урынында үз-үзен тотуга карата куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы,«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 29 мартындагы 25-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды**:

1. Зеленодольск муниципаль районы Советының 2018 елның 9 июлендәге 313 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында хезмәт (вазыйфаи) урынында үз-үзен тотуга карата куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.3 пунктындагы «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) коррупциягә каршы тору максатларында муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан, чикләүләр һәм тыюларны булдырмау турында яисә мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турында таләпләр (алга таба - хезмәт тәртибенә һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләр) 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы көрәш турында» 273-ФЗ номерлы Федераль закон, башка федераль законнар белән билгеләнгән йөкләмәләрне үтәүне тәэмин итүдә;»

1.2. 3.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле «е» пунктчасы белән тулыландырырга :

«е) муниципаль хезмәткәрнең, муниципаль вазыйфаларны биләгән затның хезмәт тәртибе таләпләрен һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын

җайга салу турындагы таләпләрне үтәүгә каршы килә торган үзенә бәйле булмаган хәлләр барлыкка килү турында хәбәрнамәсе.

1.3. 3.2.4. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2.4. Әлеге Нигезләмәнең «б» пунктчасының бишенче абзацында һәм 3.1 нче пунктның «е» пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамәне карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән бәяләмәләр әзерләү гамәлгә ашырыла.

1.4. 3.2.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2.5. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы икенче абзацында "б" пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьне карау нәтиҗәләре буенча яисә әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы бишенче абзацында "б" һәм "д" һәм "е" пунктчаларында күрсәтелгән хәбәрнамәләр буенча мотивлаштырылган бәяләмә әзерләгәндә, комиссия мөрәҗәгать яисә хәбәрнамә тапшырган муниципаль хезмәткәрләр белән әңгәмә уздырырга, аннан язмача аңлатмалар алырга, ә җирле үзидарә органы җитәкчесе яисә аның урынбасары, махсус шуңа вәкаләтле вәкилгә, билгеләнгән тәртиптә дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынучы оешмаларга рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрергә мөмкин, "Посейдон" коррупциягә каршы көрәш өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасын кулланырга, шул исәптән рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрү өчен дә. Мөрәҗәгать яисә хәбәрнамә, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар, мөрәҗәгать яисә хәбәрнамә алынган көннән алып, җиде эш көне эчендә комиссия рәисенә тапшырыла. Рәсми мөрәҗәгать юлланган очракта мөрәҗәгать яисә хәбәрнамә, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар мөрәҗәгать яисә хәбәрнамә кергән көннән алып 45 көн эчендә комиссия рәисенә тапшырыла. Күрсәтелгән вакыт озайтылырга мөмкин, әмма 30 көннән дә артмый.»

1.5. 3.2.6 пунктындагы а) пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

а) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгатьтә бәян ителгән мәгълүматны яисә әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының бишенче абзацында һәм «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән хәбәрнамәне ;

1.6. 3.2.6 пунктындагы в) пунктчасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«в) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне һәм хәбәрнамәләрне яисә әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының бишенче абзацында һәм «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән хәбәрнамәләрне алдан карау йомгаклары буенча дәлилләнгән нәтиҗә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3.9, 3.10.3 һәм 3.11.1 пунктлары нигезендә карарларның берсен кабул итү яисә башка карар кабул итү өчен тәкъдимнәр.

1.7. 3.3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.2. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән хәбәрнамәләр, кагыйдә буларак, комиссиянең чираттагы (план) утырышында карала.»;

1.8. 3.4 пунктының икенче абзацында «б» пунктчасы белән» сүзләрен «б» һәм «е» пунктчалары белән» сүзләренә алмаштырырга;

1.9 пунктының 3.4.1 пунктындагы «а» пунктчасында ««б» пунктчасы белән» сүзләрен ««б» һәм «е» пунктчалары белән» сүзләренә алмаштырырга;

1.10. түбәндәге эчтәлектәге 3.10.4. пункт белән тулыландырырга:

«3.10.4. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы "е" пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) муниципаль хезмәткәргә бәйле булмаган хәлләр барлыкка килү һәм аларның хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турында таләпләрне үтәве мөмкин булмау арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булуны танырга;

б) муниципаль хезмәткәргә бәйле булмаган хәлләр барлыкка килү һәм аларның хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турында таләпләрне үтәве мөмкин булмау арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булмауны танырга.»;

1.11. 3.11.пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.11. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «а», «б», «г», «д» и «е» пунктчаларында күрсәтелгән мәсьәләләрне карау йомгаклары буенча, моңа нигезләр булган очракта, комиссия әлеге Нигезләмәнең 3.11-3.15.1, 3.17-3.18 пунктларында каралганнан башкачарак карар кабул итә ала. Мондый карарны кабул итүнең нигезләре һәм сәбәпләре комиссия утырышы беркетмәсендә күрсәтелергә тиеш.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының (http://pravo.tatarstan.ru) хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) мәгълүмат сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы,**
**Советы рәисе** **М. П. Афанасьев**